ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, 423964,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 2 08.11.2022

Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк торак пунктында 2023 елда үзара салым кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003ел 6 октябрендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 ноябренә 11.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Көрәш-Бүләк авылы, Совет урамы, 9А йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге, Көрәш-Бүләк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районыныңБәйрәкәтамак авыл җирлеге Көрәш-Бүләк авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда үзара салым кертүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә ризалыгыгыз бармы, моңа көндезге формада белем алучы студентлар, I төркем инвалидлар; БВ сугышында катнашучылары, Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр керми һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән сез ризамы:

- Көрәш- Бүләк торак пунктында авыл клубы территориясен киртәләү (төзелеш материаллары сатып алу,килешү буенча эш хакы түләү);

-җирлек юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы” на веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru; Ютазы муниципаль районының веб-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында веб-адрес буенча: www.yutaza.tatar.ru кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә.

4. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

"Бәйрәкәтамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В.Әхмәтов